# «КЕНДЕК АПАСЫ» — ВЕНЕРА

Диләрә БУЛГАКОВА.

*Бер мизгел - бер гомер*
*“Бисмилла” дип бусагадан*
*атлыйм,*
*Догаларым барлыйм юлыма.*
*Минем нәнәем, кендегемне*
*кискәч,*
*“Бисмилла”, - дип алган*
*кулына.*

Бөтен эшенә “Бисмилла” дип тотынучы кешеләрне беләм мин. Шуларның берсе - зур тәҗрибәле, олы хөрмәткә лаек булган табиб Венера Сәет кызы Хисматова үзенең хезмәт елларында “Бисмилла” әйтеп, дөньяга беренче аваз салучы ничә дистә сабыйның кендеген кисте икән, исәпсез күптер.

- Мин ана булырга җыенган хатын-кызларга хөрмәт белән сокланып карыйм. Чөнки ул шушы якты дөньяга бәбиен тудыра, Ана була! Ходайга шөкер, мин үземнең язмышым һәм һөнәрем белән канәгатьмен. Ходай тәгалә миңа ярдәм итте, сансыз күп сабыйларның барсының да “Бисмилла” әйтеп кендекләрен кистем. Чөнки кечкенәдән үзем дә иманлы гаиләдә үстем. Яшь вакытта ук белгән догаларны кабатлап йөри идем. Бер Аллаһтан гына ярдәм сорап яшәдем, эшләдем, - ти табиб.

Венера ханым Борай районы Яңа Ялдәк авылында дөньяга килгән. Бик матур, мәхәбәтле гаиләдә үсә. Әнисе Зәйнәп Юныс кызы җиде балага гомер бирә. Әтисе Сәетгали Юныс улы тирә-якка билгеле, сәләтле, дан казанган чәчән була. Табыннарда үзе иҗат иткән мөнәҗәтләрне әйткән, олы йөрәкле чәчәнне “Әүлия бабай” дип йөрткәннәр. Сугыш ветераны була ул. Бөтен балаларына да белем бирергә тырыша. Арада зирәклеге, сабырлыгы белән аерылып торган Венерасы яшьли шигырьләр яза, бәйләмгә оста була. Хәзер җиде баладан бер Венера ханым гына үткәннәрне искә алып яшьләрен йота.

Озын чәчләрен толымга үреп йөрткән укуда тырыш кыз табиб булу турында хыяллана. Урта мәктәпне яхшы билгеләренә генә тәмамлаганнан соң, Бөредә фельдшер-акушерлык белгечлеге буенча укый. 1960 елда дипломлы яшь белгеч эшкә юллама ала. Кызны үзенең туган яклары - Борайга, Иске Бикмәт авылына эшкә җибәрәләр.

Авыл кешеләренең саулыгы әлегә тәҗрибәсез, әмма белемле һәм максатчан кыз кулларына ышандырып тапшырыла. Шуны аңлаган Венера Сәет кызы белемен халык медицинасы серләре һәм Әбугалисина ысуллары белән баетып, кыю гына эшләп китә. Иске Бикмәт, Силасау, Тукран, Калмык кебек өч-дүрт авыл кешеләренең саулыгын саклау өчен яшь кыздан зур белем, сабырлык, тырышлык таләп ителә. Елның кайсы мизгелендә дә аңа авыл араларын күп тапкырлар җигүле атка утырып та, җәяүләп тә узарга туры килә. Чибәр ак йөзле, сөйкемле, белемен эшкә җиккән тырыш, әллә нинди авыруны да дәвалап җибәрерлек тәмле телле, йомшак сүзле табиб кызның ярдәм итәренә кешеләр ышанып килә.

Күп тә үтми, яшь аналарга бәби табарга ярдәм иткән докторны яратып “Кендек апасы” дип атый башлыйлар. Үз һөнәренә гашыйк яшь табиб көнен-төнгә ялгап, тирә-як авылларга йөгереп һәр кешенең саулыгын кайгыртып чаралар күрә. Ашыгыч ярдәм кирәк булганнарына машина табып, һич югында ат белән үзәк дәваханәгә урнаштырып кайта. Алар савыгып кайтканча хәләхвәл белешеп тору аның өчен изге буруч санала.

Төп акушерлык пункты мохитен бизәргә дә вакыт таба ул. Тирәләп агачлар утырта. Саулыгына зарланып килгән кешеләрне иртә яздан кырауллы көзгә кадәр аллы-гөлле чәчәкләр иркәләп каршылар була. Ак күңелле кыз мәхәббәтен дә шушында таба. Фаязның әти-әнисе Кәримә апа белән Фәйзрахман абзый доктор киленнәрен киң колач белән каршылыйлар. Венера Сәет кызы аларны соңгы көннәренәчә үз күреп тәрбияли, соңгы юлга озата. Фаяз белән Венера аларга ике оныкъ - Радик белән Динараны бүләк итәләр. Сабыйларны тәүге гомер минутларында иркәләп кулына алучы, “Бисмилла”сын әйтеп кендекләрен кисеп ак биләүгә салучы Венера ханым үзе дә бер-бер артлы ана булу шатлыгын кичерә.



Гомер юллары ак күңелле кешеләр өлешенә дә сикәлтәләр тезә. Язмыш Венера ханымның да рухи канатларын каерып сындырмакчы була. Әмма ул сыгыла-сына торганнардан булмый. Ике баласын белән Миякә районына күченә, дәваханәдә эшли башлый. Бирегә ул чынлап та язмышы булыр кешесен очрата. Анестезиолог Шәүкәт Хисамов белән операцион шәфкать туташы Венера Сәет кызы бер гаилә булып яши башлыйлар.

- Гомерләр агышы бик үзенчәлекле икән ул. Икенчегә гаилә коргач тагы бер кызыбыз - Вика дөньяга килде. Хезмәт бурычлары буенча Красный - Ярга күчкәч, ирем - баш врач, мин медпунктта үз эшемне дәвам иттем. Хаклы ялга чыкканчы яраткан эшебезгә тогры калдык.

Безнең гаиләне табиблар династиясе дисәк тә дөрес булыр. Улым Радик “Алаплат” - күзләрне дәвалау үзәгендә баш табиб ярдәмчесе. Аныңчы танылган күз табибы Мулдашевта хирург булып эшләде. Кызым “Йоматау” санаторийнда табиб. Күңелгә шатлык өстәп торучы алты оныгым, бер туруным бар. Кияүләрдән дә ундык. Эчмиләр, тартмыйлар. Бөтен дини бәйрәмнәрне бергә уздырабыз. Аллага шөкер, безнең Красный Яр авылында, Уфа тирәсендә үзенчәлеге белән аерылып торган мәхәлләбез бар. Имам-хатыйбыбыз Фәнил Малик улы Садыйков дини бәйрәм-нәрне, җомга намазларын матур итеп оештыра, намазлар укыла. Безнең авылда төрле милләт кешеләре яши. Мөселманнар җыелыша торган изге Аллаһ йортыбыз бигрәк күркәм. Матур яшибез, Аллага шөкер, - ди гомер юлын саф күңел белән кешеләр турында хәстәрлек күреп узган табиб Венера Сәет кызы.

Аның тырыш хезмәтен Хөкүмәт тә югары бәяләгән. Югары категорияле табиб исеме һәм сансыз күп мактау кәгазьләре тыңгысыз хезмәт еллары турында сөйли. Ирлехатынлы табиблар гаиләсен тирә-якта күпләр белә. Ярдәм кирәк вакытта да, хаклы ялда дип тормыйлар, киңәш сорап аларга киләләр.

Венера Сәет кызы белән мин моннан егерме еллар элек, Красный Яр китапханәсендә әдипләр белән уздырылган бер кичәдә танышкан идем. Анда язучыларга һәм Гражданнар сугышының легендар герое В. Чапаевка багышланган бай стендны күреп сокланган идек. Боларны шул камиллеккә җиткерүдә күп көч салучы да шул ук Венера ханым булып чыкты. Авыл халкы тормышындагы бөтен мәдәни чаралардан алынган фотосурәтләрнең тарих битләренә энҗедәй тезелеп баруы да аның хезмәте булуын белдек.

Күп еллар үтте. Менә язмыш безне тагы китереп очраштырды. “Йоматау” санаториенда без бер-беребезне таныдык. Ата-бабаларның туган якларына зират кылырга кирәк дип әйтүемә ул аптырап китте.

- Минем дә Борай районының Иске Ялдәк дигән яшел чирәмле, җырчы чишмәләре белән танылган авылда тәүге эзләрем калды бит, - диде, бик сөенеп.

Ял вакыты тәмамлангач, без аның белән Иске Бикмәткә кайттык. Мәчетенә барып корбан чалдырдык. Халкын чакырып Коръән укытырга насыйп булды.

Бу изге эшне оештыруда һәм уздыруда Борайның Ак мәчет һәм Кызыл мәчет хаҗилары, имам-хатип Зарипов Рифат вә Илдар хәзрәтләрнең ярдәме зур булды. Коръән сурәләре, вәгазьләр укып искиткеч матур, җылы очрашу оештырдылар. Ходайның рәхмәте төшсен аларга. Аннан хәзрәтләребез безне Иске зыяратка алып бардылар. Газиз кешеләребез рухына дога кылдык, сурәләр укыйды. Җәйнең озын бер көненә чак сыеп беткән матур эчтәлекле бәйрәмнең һәр минуты искиткеч үзенчәлекле булды.

Әйтерсең ул алдан әзерләнгән сценарий буенча барды. Бу көнне вакыт аермасы да җуелды. Авыл кешеләре белән ихлас аралашу вакытларында Венера ханым янына кырыктан чак кына өстәрәк яшьтәге туташ-ханымнар елмаеп килеп күрешеп хәл сорашкан мизгел аеруча дулкынландыргыч булды. Аларның һәркайсының серле карашыннан аңладым: алар кайчандыр “Кендек апа”лары кулларында тәүге сулыш алган, тәүге авазларын зур дөньяга яңгыраткан кызлар иде. Нинди очрашу!..

---

# *Ике туган хаҗия*

Октябрь аеның тәүге җомгасында Нижегородка бистәсендәге Мөнирә мәчетендә мөселман хатын-кызларының оешмасы агъзалары җыелды. Унда дин әһелләре, мөгаллимәләребез, “Гуфран”, Мәрьям Солтанова мәчетләреннән, Сипайлово, Шакша бистәләре мәхәлләләреннән 30дан артык хатын-кыз килгәйне. Улар арасында бер туган хаҗия Гөлфәния белән Нәсия дә бар иде.

Өйлә намазын бергәләп укыганнан соң, Мөнирә абыстаебыз сүз башлады. “Намаз Аллаһка булган иманыбызны ныгыта”, - дип ул рәкәгать, сөннәт, фарыз намазлары турында җинтекләп сөйләде.

Аннан соң Мәрьям Солтанова мәчетеннән килгән мөгаллимәләребез ата-бабаларыбызның изге йолаларын, гөреф-гадәтләрен саклап калу макчатыннан изге китапларын җыеп, мәчетнең булмәсендә музей ачу турында фикер йөртте. Уларны барсы да хуплады.

Гафури районындагы аграр совхозыннан ике тапкыр хаҗга барган Галия Гали кызы хаҗ саваплары, “зәм-зәм” суы турында дулкынланып сөйләде.

...Кәгъбәтулла, җәннәт ташлы
Кәгъбәтулла
Тәүге мәчет - Аллаһ йорты күккә ашкан.
Пәйгамбәрләр, дин әһелләр, әүлияләр,
Дога кылып төзегәннәр изге таштан.
Бер Аллаһка ялваралар яшен түгеп,
Мөхәммәтнең өммәтләре кыла тәваф
Сәҗдә кыла үлән, яфрак, агач, гөлләр,
Бар тереклек, тау-ташлары,
Сөбханаллаһ!

Тәүге мәчет Аллаһ йорты Кәгъбатулланы күреп хаҗ кылган хаҗияләребез хәзер сансыз, Аллага шөкер!

Нәсия вә Гөлфания ике тапкыр хаҗга барырга насип булган. Уңган ханымнар соклангыч табигатьле Каридел районы Муллакай авылында иманлы гаиләдә дөньяга килгән. Әниләре Гәкифә Нургали кызы өч кыз балага гомер бирә. Әтиләре Хайретдин Габдулла улына сабыр Гәкифә белән бары алты ел гына бергә яшәп калырга насыйп була. Ул гаиләсен калдырып, сугышка китә һәм башка туган якларына әйләнеп кайта алмый. Гәкифә гомер буе Хайретдиненә тогры калып, Үрмиязда йөшәүче олы кызы Рәүфәсендә бер намазны да калдырмыйча, 79 яшендә балаларына фатыйхасын биреп вафат була.

Авыр елларның камчылары да читләп үтми, ачлык-ялангачлык, ятимлек капка төпләрендә сагалый. Әммә бәләкәйдән дога, сүрәләр ишетеп үскән тырыш, сабыр кызлар белем алырга омтылалар. Буыннары да ныгытып өлгермәгән балалар кулларыннан килгәнчә әниләренә колхоз эшендә дә, өйдәдә дә ярдәм итә. Муллакайда 4 класс укып ары Султанбәк мәктәбен тәмамлыйлар. Нәсия металлургия техникумын тәмамлап, диплом алгач, бергә укыган Таһирҗан белән Ташкенттың Алмалык өлкәсенә эшкә җибәрелә. Шунда эшләгәндә яшьләр кавышып, 36 ел бергә татыу гомер кисерә, бер ул, бер кыз үстерә. Гаилә тыуган ягына әйләнеп кайта. Уфаны сагнып кайткан абыстай тәүге көнне үк Алла йортына йүнәлә. Яшли дингә омтылган Нәсия Тукай мәчетенә юл сала. Тәүләп Касыйм хәзрәттән белем алса, ары “Ихлас” мәчетендә - Ирек хәзрәттән, ары Дулкын хәзрәттән дин дәресләре өйрәнә.

- Аллага шөкер, 2006 елда хаҗ кылырга насыйп булды. Елына ике тапкыр Корьән ашлары уздырып, чалдырам, - дип куана үзе. - Балаларым безне биктә хөрмәт итеп, зурлап, ярдәм итеп торалар. Ана-ата өчен шушы олы бәхет түгелмени? Әле кулымдагы Изге Корьән Кәримне өйрәнәсе дә өйрәнәсе, - дип кулындагы китапны кысып куйды Нәсия хаҗия.

Тырыш сеңлесе Гөлфәниянең язмышы да бер үк үзләре салган сукмактан тайпылмаган. 10 класны тәмамлагач, халык хуҗалыгы техникумын яхшы билгеләргә генә тәмамлый. Тәүдә Дуван районында, ары Балтач районында конторларда, аннан соң, Уфа шәһәрендәге предприятиеларның берсендә бухгалтер булып эшләп, хаклы ялга чыга. Үзе белән бергә укыган чибәр егәрле егет Мөкәмия Мәрвия углы белән гаилә корып, 46 ел тату гомер кичерәләр. Ике ул үстерәләр.

Бер тапкыр да намазларын, уразаларын калдырмаган хаҗияләргә сокланып рәхмәттән башка ни әйтәсең?

Мөселман хатын-кызлары оешмасында Галия хаҗия хаҗ турында бәйән итсә, Нәсия абыстай бала дөньяга килгәч, нарасыйларыбызга мөселман исемнәре кушу хакында сөйләде. Ә Гөлфәния мәетне соңгы юлга озату - җеназа намазы турында җентекләп аңлатты.

Бу биктә кирәкле, киңәшләргә бай булган мөселман хатын-кызлар оешмасы аена бер тапкыр, һәр айның беренче җомга көнне җыелышабыз. Бергәбергә киңәшләшеп, кайгы-хәсрәтләребезне бүлешеп, яхшы ниятләр белән очрашабыз.

Дөньялар имин булсын, бергә-бергә намазлар укып, тагы ла очрашырга язсын, Амин!